СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 22 мае Әгерҗе шәһәре № 37-8

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2012 елның 27 гыйнварындагы 11-3 номерлы «Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә җир кишәрлекләрен түләүсез алуга хокуклы гражданнарга җир кишәрлекләренең чикләмә күләмнәре турында"гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 22 декабрендәге 111-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Әгерҗе районы прокурорының 28 мартындагы 02-08-01/30 санлы протестын карап, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2012 елның 27 гыйнварындагы 11-3 номерлы "Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә җир кишәрлекләрен түләүсез алуга хокуклы гражданнарга җир кишәрлекләренең чикләмә күләмнәре турында"гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- беренче абзацта «дача төзелеше» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны http://PRAVO.TATARSTAN.RU Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының җир һәм милек мөнәсәбәтләре, экология, табигый ресурслар һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы,
Совет Рәисе В. В. МАКАРОВ